**МИНИСТЕРСТВО ЗДРАВООХРАНЕНИЯ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫНЫҢ СӘЛАМӘТЛЕК САКЛАУ МИНИСТРЛЫГЫ**

**ПРИКАЗ** **БОЕРЫК**

26.09.2022 Казан шәһ. № 2565

Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгының 28.02.2022 № 500 «Татарстан Республикасында өлкән халыкка кискен коронар синдром вакытында медицина ярдәме күрсәтүне оештыру турында» боерыкка кушымта № 1гә үзгәрешләр кертү турында

Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгы һәм Удмуртия Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгы арасындагы Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы территориясендә яшәүче кискен коронар синдром белән, баш мие кан әйләнешен кискен бозылуы белән пациентларга, йөкле хатыннарга, бала табучыларга һәм аларның яңа туган балаларына медицина ярдәмен оештыруны камилләштерүгә юнәлдерелгән чараларны гамәлгә ашыру турындагы 07.07.2022 № 0521 килешүне үтәү йөзеннән боерык бирәм:

Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгының «Татарстан Республикасында өлкән халыкка кискен коронар синдром вакытында медицина ярдәме күрсәтүне оештыру турында» 28.02.2022 № 500 боерыгына «Кардиохирургия тыкшынуларын үткәрү өчен үз структурасында диагностиканың һәм дәвалауның рентгеноэндоваскуляр методлары бүлеге булган, Татарстан Республикасы медицина оешмаларына беркетергә тәкъдим ителгән муниципаль берәмлекләр» кушымта № 1гә үзгәрешләр кертергә, аны яңа редакциядә бәян итәргә (кушымта итеп бирелә).

Министр М.Н.Садыйков

Э.Х.Янгирова
8 (843) 231-79-30

ТР Сәламәтлек саклау министрлыгының 28.02.2022 № 500 боерыгына
Кушымта № 1
(Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгы боерыгы редакциясендә 26.09.2022 № 2565)

Кардиохирургия тыкшынуларын үткәрү өчен үз структурасында диагностиканың һәм дәвалауның рентгеноэндоваскуляр методлары бүлеге булган, Татарстан Республикасы медицина оешмаларына беркетергә тәкъдим ителгән муниципаль берәмлекләр

| Беркетелгән территорияләр исемлеге | Медицина оешмаларының атамасы (ЧКВ үткәрү өчен) | Медицина оешмаларының атамасы (кардиохирургия тыкшынуларын үткәрү өчен) |
|---|---|---|
| Аксубай районы;<br>Алексеевск районы;<br>Әлки районы;<br>Әтнә районы;<br>Балтач районы;<br>Кукмара районы;<br>Лаеш районы;<br>Нурлат районы;<br>Балык Бистәсе районы;<br>Саба районы;<br>Спас районы;<br>Теләче районы;<br>Чистай районы | «Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгының Республика клиник хастаханәсе» ДАССУ | «Төбәкара клиник-диагностика үзәге» ДАССУ |
| Апас районы;<br>Яшел Үзән районы;<br>Кама Тамагы районы;<br>Тәтеш районы;<br>Казан шәһ.:<br>Вахитов районы;<br>Совет районы, Н.Рахлин ур., 5 адресы буенча урнашкан «Медицина диагностик үзәге» ҖЧҖ филиалы хезмәт күрсәтү территориясен дә кертеп (Азино2, Танкодром, Дәрвишләр бистәсе, Нагорный бистәсе микрорайоннарыннан һәм «8нче | «Казан (Идел буе) федераль университеты» ЮБ ФДАМУ МСЧ | «Казан (Идел буе) федераль университеты» ЮБ ФДАМУнең МСЧ |

| | | |
|---|---|---|
| номерлы Шәһәр сырхауханәсе» ДАССУ 3 терапия бүлегенә беркетелгән территориядән тыш);<br>Киров районы | | |
| Арча районы;<br>Казан:<br>Совет районы: Азино-2 микрорайоны, «20нче шәһәр сырхауханәсе» ДАССУ медицина хезмәте күрсәтү өчен беркетелгән территория;<br>Танкодром, Казан шәһәренең «Профессор К.Ш.Зыятдинов исемендәге 18нче Үзәк шәһәр клиник хастаханәсе» ДАССУ 2нче сырхауханә бүлегенә медицина хезмәте күрсәтү өчен беркетелгән территория;<br>Идел буе районы | «Төбәкара клиник-диагностика үзәге» ДАССУ | «Төбәкара клиник-диагностика үзәге» ДАССУ |
| Буа районы;<br>Югары Ослан районы;<br>Биектау районы;<br>Чүпрәле районы;<br>Кайбыч районы;<br>Питрәч районы;<br>Казан:<br>Совет районы: Дәрвишләр бис., Нагорный бис., «8нче шәһәр сырхауханәсе» ДАССУ 3 терапия бүлегенә медицина хезмәте күрсәтү өчен беркетелгән территория, «Ситидок-Эксперт Казан» ҖЧҖ;<br>Яңа Савин районы;<br>Авиатөзелеш районы;<br>Мәскәү районы | «7нче шәһәр клиник хастаханәсе» ДАССУ, Казан шәһ. | «Төбәкара клиник-диагностика үзәге» ДАССУ |
| Яр Чаллы шәһәре;<br>Әгерже районы:<br>Кадыбаш ТА: Кадыбаш, Девятернә, Нарат, Иске Пәсләк, Үтәгән, Гали, Касай, Комсомол авылы.<br>Исәнбай ТА: Исәнбай, Бима, Пеләмәш, Мандык, Яңа Чыкалда авылы.<br>Красный бор УХ: Красный Бор, | «Ашыгыч медицина ярдәме хастаханәсе» ТР ДАССУ, Яр Чаллы шәһ. | «Ашыгыч медицина ярдәме хастаханәсе» ТР ДАССУ, Яр Чаллы шәһ. |

| | | |
|---|---|---|
| Зуево, Ямурза, Уразай, Салагыш, Мадьяр, Татар Чилчәсе, Азево, Кондызлы, Чәчкә, Ташлы, Шаршады, Сәхрә, Байтуган, Кадрәк, Күләгәш, Иске Чыкалды, Саклау, Ожбуй, Волково.<br>Кичке Таң ТА: Кичке Таң, Кырынды, Балтач, Барҗы Пельга, Барҗы Омга, Чишмә авылы;<br>Актаныш районы:<br>Алабуга районы;<br>Мамадыш районы;<br>Менделеевск районы;<br>Минзәлә районы;<br>Тукай районы | | |
| Әлмәт шәһәре,<br>Әлмәт районы;<br>Азнакай районы;<br>Баулы районы;<br>Бөгелмә районы;<br>Зәй районы;<br>Лениногорск районы;<br>Мөслим районы;<br>Яңа Чишмә районы;<br>Сарман районы;<br>Ютазы районы;<br>Чирмешән районы | «Әлмәт районара күппрофильле хастаханәсе» ДАССУ | «Әлмәт районара күппрофильле хастаханәсе» ДАССУ |
| Түбән Кама шәһәре,<br>Түбән Кама районы | «Түбән Кама үзәк район күппрофильле хастаханәсе» ДАССУ | «Төбәкара клиник-диагностика үзәге» ДАССУ |
| Өстәмә:<br>Әгерҗе районы:<br>Әгерҗе шәһ. Иж-Бубый, Иж-Бәйки, Биектау, Кодаш, Кыдрылы, Яңа Кызыл Яр, Мордва, Сарсак-Омга, Сәрдәле, Тәбәрле, Татар Тансары, Яңа Акхуҗа, Мукшур, Сокман, Сарсак Әрәмә, Яңавыл, Вольный Труд, Яңа Никольск, Иске Никольск, Варкләд Авыл, Яңа Бәзәкә, Көчек, Рус Шаршадасы, Еленовский, Тукай, Варклед Бодья | «Удмуртия Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгының Республика клиник-диагностика үзәге» Удмуртия Республикасы бюджет сәламәтлек саклау учреждениесе | «Удмуртия Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгының Республика клиник-диагностика үзәге» Удмуртия Республикасы бюджет сәламәтлек саклау учреждениесе |

*Искәрмә:* кардиохирургия клиникаларының берсендә коронар шунтлауны уздыруның техник мөмкинлеге булмаганда, пациент маршрутлаштыруны үтәмичә башка кардиохирургия клиникасына җибәрелергә тиеш.